**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы**
**Яңа Чыршылы авыл җирлегенең**
**Горкино торак пункты гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2024 елның 1 апреле

№ 2

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Горкино торак пунктында гражданнар җыенының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Горкино торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында»2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы (29.11.2023 №1532 редакциясендә) карары белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән,Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, 2024 елның 1 апрелендәге «Сез 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Горкино торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» карары һәм 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Горкино торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» карарына үзгәреш кертү турында 2024 елның 1 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Горкино торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Горкино торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы һәм «Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Горкино торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында» 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Горкино авылы территориясендә үлән чабу; Үзәк урам буенча иске агачларны кисү);

2) торак пункт чикләрендә җирле мәгънәдәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төү, ремонтлау, карап тоту (Горкино торак пунктында Үзәк урамда туфрак-вак таш җәелгән юлларны ремонтлау)

3) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Горкино торак пункты Үзәк урамы буенча сууткәргеч төзү)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Яңа Чыршылы поселогы, Заречная урамы, 25 йорт, Үзәк урам, 12А йорт адресы буенча

урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Яңа Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Ә.Мөхәмәтшина